БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**

**КАРАР**

7 июнь 2022 ел

№ 130

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2002 елның 26 мартындагы 65-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2019 елның 5 ноябрендәге 215 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 18 статьяның 13 абзацында «муниципаль гарантияләр буенча» сүзләрен «муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 18 статьяның 19 абзацында «... белән чагылдырылган муниципаль гарантияләр буенча» сүзләрен «... белән чагылдырылган муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 18 статьяның 23 абзацында «... бирелгән чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләр буенча» сүзләрен «... бирелгән чит ил валютасындагы муниципаль гарантияләрдән килеп чыга торган» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 53 статьяның 3 пунктына «... әгәр әлеге Кодекста башкасы каралмаган булса» сүзләрен өстәргә;

1.5. 22 статьяның 2 өлешендә «Район йөкләмәләре» сүзләреннән соң «инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә җәлеп ителгән бюджет кредитының тиешле ел ахырына файдаланылмый калган акча күләменнән тыш» сүзләрен өстәргә;

1.6. 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац өстәргә:

«гражданнарның бюджет процессында катнашуы;»;

унберенче - ундүртенче абзацларны уникенче - унбишенче абзацлар дип санарга;

1.7. 8 статьяның 9 пунктындагы 4 абзацына «бюджетның бердәм счетында калган акчалар белән идарә итү операцияләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

1.8. 29 статьяның 27 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Принципалның кредит (заем, облигациядән тыш) буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итүче муниципаль гарантия кредит шартнамәсендә (займ шарнамәсендә) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантияне бирү турында шартнамәдә кредиторга (займга бирүчегә) күрсәтелгән кредит (займ) акчаларын максатчан файдалануны үз ягыннан контрольдә тоту йөкләмәләрен билгеләү шарты белән бирелә.»;

1.9. 40 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тиешле бюджет керемнәренең гомуми күләмен үзгәртүгә китерә торган һәм бюджет турында закон проектын (карарларны) закон чыгару (вәкиллекле) органына керткәннән соң кабул ителгән Район Советының норматив-хокукый актлары агымдагы финанс елына һәм план чорына бюджетка үзгәрешләр керткәндә чираттагы финанс елында агымдагы финанс елы күрсәткечләре өлешендә исәпкә алына.»;

1.10. 29 статьяның 16 пунктындагы 5 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга;

1.11. 29 статьяның 4 пунктында "һәм үтәлә" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.12. 24 статьяның 2 пунктында "һәм үтәлә" сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. 29 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын күздә тотмый торган муниципаль гарантия фәкать акцияләренең (өлешләренең) 100 проценты тиешле гавами-хокукый белемгә (гарантка) ия булган хуҗалык җәмгыяте йөкләмәләре, мөлкәтләре тиешле гавами-хокукый берәмлек (гарант) милкендә булган муниципаль унитар предприятиенең йөкләмәләре генә тәэмин ителергә мөмкин, ә гарантның принципалга карата регресс таләбе хокукын күздә тотмый торган Россия Федерациясе дәүләт гарантиясе шулай ук Россия Федерациясе тарафыннан оештырылган (төзелгән) дәүләт корпорациясе яисә дәүләт компаниясе йөкләмәләре дә тәэмин ителергә мөмкин.»;

1.14. 29 статьяның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Принципалның кредит (займ, шул исәптән облигация займы) буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган муниципаль гарантия бары тик муниципаль гарантиядә күрсәтелгән, гарантның алдан язма ризалыгыннан башка үзгәртеп булмый торган төп йөкләмә шартлары гарантның алдан язма ризалыгыннан башка үзгәртелгән очракта һәм (яисә) аңа карата Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) кредит шартнамәсе һәм кредит буенча муниципаль гарантия бирү турында шартнамә нигезендә кредитор тарафыннан кредит акчаларының максатчан кулланылышын контрольдә тоту гамәлгә ашырыла торган, муниципаль гарантия белән тәэмин ителгән кредит (займ, шул исәптән облигация займы) чараларын максатсыз файдалану очрагында гарант тарафыннан кире алынырга тиеш.»;

1.15. 17 статьяның 16 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.16. 57 статьяның 8 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.17. 57 статьяның 4 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.18 54 статьяныц 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бюджет исәбенең һәм бюджет хисаплылыгының бердәм методологиясе әлеге Кодекс нигезләмәләре нигезендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә.»;

1.19. 51 статьяның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Бюджет язмаларын төзү һәм алып бару тәртибе бюджет акчалары баш бүлүчесенең (бүлүчесенең) чыгымнар төрләре төркемнәре (төркемнәре һәм элементлары) буенча расланган бюджет йөкләмәләре лимитларын җентекләүне (детальләштерүне) гамәлгә ашыру хокукын яисә бурычын билгеләргә мөмкин.»;

1.20. 51 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Чыгымнар буенча бюджет язмасы һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары күрсәткечләре, әлеге Кодексның 190 һәм 191 статьяларында каралган очраклардан тыш, чираттагы финанс елы башына кадәр ведомство буйсынуындагы бюджет акчаларын бүлүчеләргә һәм (яисә) алучыларга җиткерелә.»;

1.21. 50 статьяның 4 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

1.22. 50 статьяның 2 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- бюджет һәм акчалата йөкләмәләрне кабул итү һәм исәпкә алу;»;

1.23. 49 статьяның 5 абзацында «салымнар һәм җыемнар турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.24. 42 статьяның 2 пунктындагы 3 абзацында «ике айдан да соңга калмыйча» сүзтезмәсен «өч айдан да соңга калмыйча» сүзләренә алмаштырырга;

1.25. 37 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Бюджет проектларын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

- Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә юлламасындагы Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләрне) билгеле торган нигезләмәләре турында;

- Россия Федерациясе Милли үсеш максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлегенең юнәлешләрен билгели торган документлар турында;

- Россия Федерациясенең Бюджет, салым һәм таможня - тариф сәясәтенең төп юнәлешләре (Россия Федерациясе субъектларының бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре, муниципаль берәмлекләрнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре);

- социаль - икътисадый үсеш фаразы турында;

- озак вакытлы чорга бюджет фаразы турында (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проекты);

- муниципаль программалар (муниципаль программалар проектлары, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары).»;

1.26. 17 статьяның 14 абзацында «акчаларны исәпкә алу буенча» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.27. 50 статьяның 3 пунктында «түләү һәм» сүзләрен «казначылык түләүләрен башкару турында күрсәтмәләр (алга таба - күрсәтмә) һәм» сүзләренә алмаштырырга;

1.28. 50 статьяның 5 пунктында «түләү документлары» сүзләрен «күрсәтмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

1.29. 17 статьяның 16 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге кодекс нигезендә бурыч тотрыклылыгы югары яки уртача дәрәҗәдә булган займга алучылар төркеменә кертелгән муниципаль берәмлек бюджетының хисап елында үтәлеше барышында бюджет ассигнованиеләрен тулысынча куллануга бәйле рәвештә барлыкка килгән калган акчалар һәм әлеге өлешнең икенче абзаңында каралган бюджет ассигнованиеләрен арттыру суммасы арасындагы аермадан артмаган күләмдә, бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга салучы муниципаль берәмлек вәкиллекле органының муниципаль хокукый актында билгеләнгән тәртиптә кулланыла».

2. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" бастырырга һәм baltasi.tatarstan.ru Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач районы Советы рәисе Р. Р. Нотфуллин